Мәктәпкә әзерлек төркемендә “Африкага сәяхәт” дигән темага бердәм белем бирү эшчәнлегенең конспекты

Беренче категорияле тәрбияче:

Гибадуллина Зульфия Ванситовна

Максат: Рельефлы әвәләү техникасын үзләштерүне дәвам итү, эшне башкарганда хайванның үзенчәлекле билгеләрен (озын муен, озын аяклар, овал формасындагы баш) чагылдырырга өйрәтү, пространствода ориентлашуны күнектерү, вак деталь-ләр белән эшләгәндә стека куллануны ныгыту, балаларның иҗади сәләтләрен мактау, эшне башкарганда пөхтәлек, эшне ахырына кадәр башкаруны тәрбияләү.

Материал: Жираф рәсеме, һәр балага геом. фигуралар салынган поднос, әвәләү өчен такталар, төсле камыр, картон.

Алдан башкарылган эш: Рельеф белән таныштыру, “Африкада яшәүчеләр” темасына әйләнә-тирә белән таныштыру дәресе, “Җылы якта яшәүчеләр” темасына рәсем дәресе үткәрү, жираф уенчыгы карау.

Шөгыль барышы:

-Балалар, әйдәгез түгәрәккә басып бер- беребезгә хәерле иртәләр

телик әле.

Хәерле иртә, миңа!

Хәерле иртә, сиңа!

Хәерле иртә, безгә!

Хәерле иртә, сезгә!

-Балалар, хәзер елның кайсы вакыты?

-(Кыш)

-Әйе,бик дөрес, балалар.

-Ә бүген көн нинди?

-(Салкын)

-Ә сезнең җылы якка барасыгыз киләме?

-Нинди җылы якларны беләсез?

-(Азия, Африка, Төркия, Испания, Кырым, Греция, Тунис)

-Без сезнең белән кая барырбыз икән?

-(Африкага).

-Алайса без сезнең белән нәрсәгә утырырбыз икән?

-(Самолетка.)

-Кулга- кул тотынып күзләрне йомыйк.(Музыка яңгырый, агачлар, уенчыклар куела.)

-Менә без килеп тә җиттек, карагыз нинди матур агачлар үсеп утыра монда, нинди агачлар алар?

-(Пальмалар.)

-Карагыз әле нинди хайван икән ул балалар?

-Монысы нинди хайван?

-(Мөгезборын, көңгерә, фил, дөя, леопард, гепард, маймыл, арыслан.)

-Мин сезгә бер табышмак әйтәм тыңлагыз әле.

-Жәлләсәм дә аны кайчак,

И муены озын дип,

Рәхәттер ул озын булгач,

Андый озын муен җирдә

Фәкать анда гына бит.

-Нәрсә икән ул балалар?

-(Жираф.)

-Әйе, бик дөрес. (Рәсеме күрсәтелә.)

-Әйдәгез без аны карап китик.

-Аның гәүдәсе нинди формада?

-(Овал формасында.)

-Муены нинди?

-(Озынча, сузылган.)

-Башы нинди формада?

-(Овал формасында.)

-Аяклары нинди?

-(Нечкә, озын.)

-Без тагын нәрсәләрне әйтмәдек?

-(Колаклары, мөгезләре, тояклары, койрыгы кисточкасыман.)

-Ә хәзер ял итеп алыйк.

-Озын муен, озын аяк,

Йөри ул җитез атлап,

Үлән түгел, яфрак ашап,

Арысланнан гел качып.

-Балалар, безнең жираф никтер күңелсез, бәлки аңа дуслар кирәктер?

-Өстәлләр янына утырыгыз, подносларда нинди геом. фигураларны

күрәсез?

-(Овал, турыпочмак, өчпочмак.)

Ә хәзер геом. фигуралардан жираф фигурасы төзегез.

-Молодцы булдырдыгыз.

-Без бүген сезнең белән жирафның барельефын ясыйбыз.

-Нәрсә дигән сүз ул барельеф?

-(Ул әйберне картонда кабартып ясау.)

-Нинди геом.фигуралардан әвәләргә кирәклекне без сезнең белән

өстәлдә жирафны төзеп белдек, ә әвәләү күнекмәләре сезнең

каршыгызда.Камырны картонга ябыштырыр алдыннан су белән

юешләргә онытмагыз.

-Ә хәзер әвәләр алдыннан кулларны ял иттереп алабыз.

Без инде хәзер зурлар

Күп эшли безнең куллар,

Без идән дә юабыз,

Һәм керләр дә юабыз

Тиздән үсеп җитәрбез,

Шунда эшкә китәрбез.

-Без сезнең белән нәрсә ясадык балалар?

-Әйе, дөрес жирафның барельефын ясадык.Моның кадәр дуслар булгач безнең жирафыбызга да инде күңелсез булмас.

-Сез бүген бик тырыштыгыз, молодцы, шуңа күрә эшләрегез дә

бик матур килеп чыкты. Инде безгә бакчабызга кайтырга вакыт,

күзләрне йомып самолетка утырыйк.

-Дәресебез тәмам.